# Шигърият шәхестән башлана...



Иҗат – хыял, үз хыялыңны үзең куып җитәргә омтылу. Ә шагыйрьләр күңеле бигрәк тә хыялга, хискә бай була. Тумыштан күңеленә шагыйрьлек уты салынган кеше башкача яши алмый, ул гомер буе шагыйрь булып кала. Биклән авылында яшәп иҗат итүче шагыйрәбез, драматург, бик күп популяр җырлар, шулай ук Тукай районы гимны авторы, ТР Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы, «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» дигән күкрәк билгесе иясе Рәзинә Сәетгәрәева шундыйларның берсе. Иштирәк авыл китапханәсендә үткән әдәби кичә нәкъ аңа багышланды да инде.

Шигърият бәйрәме Рәзинә Сәетгараеваның “Күңел сандыгы” дип исемләнгән шигыре белән башланып китте. Шагыйрәбезне якты йөз белән каршы алган Иштирәк авыл халкы кичә барышында кунагыбызның “күңел сандыгында” булган яңалыклары, казанышлары, уй-хыяллары, серләре белән танышты.

Рәзинә апаның шигърияте күпкырлы, үзенчәлекле. Аның иҗатында туган җир, туган нигез, туган туфрак темалары белән беррәттән авыл моңы, авыл матурлыгы, яшьлек еллары, мәхәббәт темалары да киң урын алган. Тормыш дәверендә очраган гаделсезлек, кимчелекләр белән килешмичә, алга килгән авырлыкларга бирешмичә яшәргә өндәүче шигырьләрен дә укучы үз итә, югары бәя бирә.

Ветеран укытучыбыз - Земфира Әбүзәр кызы Гарифуллина, мәдәният йортыбызның режиссеры - Гүзәл Фәһим кызы Һадиева – килгән кунакларны шагыйрәнең яңа иҗат җимешләре белән таныштырды. Шагыйрә үзе дә безгә йөрәгеннән чыккан шигырьләрен, яңа җырларын башкарды.

Шагыйрәнең җырларын, шигырьләрен күңел биреп тыңлап, аның тормыш юлы һәм иҗаты белән якыннан танышып, аның яшьлек елларына, балачагына кайтып килдек.

Кичәбез шундый матур, җылы аралашу мохитендә узды, хәтта вакытның шулай тиз үтеп киткәнен дә сизмәдек.

Гомумән, без- иштирәклеләр бик тә рәхмәтле Рәзинә апага, чөнки ул безнең зурлар һәм балалар театры өчен бик күп сәхнә әсәрләрен махсус язып бирде. Аның бик күбесе безнең авыл сәхнәсендә куелды, районкүләм һәм республикакүләм бәйгеләргә тәкъдим ителде. Иң отышлылары дип «Тәүбә йорты» пьесасын атар идек. Шулай ук безнең мәдәният йортында эшләп килүче “Тамчы” балалар үрнәк коллективы да аның “Җенле күл”, “Тылсымлы төн”, “Вөҗдан газабы”, «Бөркет туганда» әсәрләре белән бик уңышлы чыгыш ясадылар. Нәфис сүз конкурсларында да Рәзинә апа безнең алыштыргысыз ярдәмчебез һәм таянычыбыз! Аның иҗат җимешләре белән Зәлия Закирова һәм Алсу Нургалиева районкүләм “Балкыш” конкурсында конферансье номинациясендә, Шамил Закиров белән Рамазан Туктаров республикакүләм “Илһам” конкурсында “Илһамлы татар иле” номеры белән, Диләрә Һадиева һәм Айзилә Зәйнетдинова “Минем көчем тирән тамырларда” шигыре белән лаеклы урыннар, мактаулы исемнәр яуладылар. Иштирәк авыл җирлеге башлыгы - Гөлнара Сәүбән кызы рәхмәтен белдереп, Рәзинә Габделбәр кызы Сәетгәрәевага “Мактау хаты” тапшырды.

Әйе милли кыйммәтләрне киләчәккә илтүдә Рәзинә апа зур иҗади көч куя. Аның тормыш юлына карасаң, һичшиксез дөрес юлда булуына инанасың. Ул бер дә авырсынмыйча, алны-ялны белми Ходайдан бирелгән талантын шигъри юллар аша, җырлар аша кеше күңеленә җиткерә!

Безнең милләтебезне, телебезне Рәзинә апа кебек шәхесләр яшәтә дә инде!

**Алия Закирова.**